ТАТАРСТАН ҮРНӘГЕ

Ил Президенты республиканы мактады

> 2

ВАТАН УЛЫ

Михаил Девятаев батырлыгы һәм аның үзе турында без нәрсә беләбез?

> 3

БАЛАЧАК ИСТӘЛЕГЕ

Редакция тарихы кайберәүләрнең балачагы белән дә тыгыз бәйле

> 3

ХА-ХА-ХАНӘ

Булмас димә, кызык-мызык, фототөрткеләр – бирелдә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 21 (28988) | Шимбә | 11 февраль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КҮРЕНМӘС ДОШМАН

Яшәеш

Соңгы елларда сөрем газы белән агуланучылар, газ шартлау очраклары турында еш ишетергә туры килә. Җиһазларга вакытында техник хезмәт күрсәтелсә, мондый хәлләр кимрәк тә булыр иде, ди газчылар. Тик, кызганыч, күбебез тикшерүчеләрне кертергә ашыкмый. Сәбәпләре нидә?

«ВТ» архивыннан

Газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү елына бер мәртәбә үткәрелә. «Газпром трансгаз Казан» оешмасы хезмәткәрләрен әллә каян танырга мөмкин. Оешманың баш инженер урынбасары Алмаз Ханнанов әйтүенчә, аларның хезмәткәрләре бертөрле кием кия. Махсус таныклыклары да бар. Түшләренә оешма эмблемасы ябыштырылган, һәрберсе QR-кодлы бейдж тага. Аңа телефонны якын китерү җитә – кем икәнлеге хакында бөтен мәгълүмат килеп чыга.

Алмаз Ханнанов аңлатуынча, хезмәткәрләр иң элек вентиляция, төтен юлларының тарту көчен тикшерергә тиеш.

– Газ җиһазларының урыныннан кучү-күчмәвен, аларның төзеклеген карыйлар, – ди ул. – Барысы да кеше иминлеге өчен башкарыла. Тик менә кулланучылар гына без киләсе көннәрне өйдә торсын иде. Газчылар техник хезмәт күрсәтүчеге турында игъланнар алдан ук язылып элене. Әмма шуңа да карамастан, фатирларга керә алмыйча тилмерәбез. Бер барабыз, икенче тапкыр киләбез. Аннары инде Татарстанның торак инспекциясенә мөрәҗәгать итәбез. Алар исә йорт хуҗаларын, безне кертмәгән өчен, административ җаваплылыкка да тарта. Кайберләрен идарәче оешма аша барыбер эзләп табабыз. Ник дигәндә, күршеләренең иминлеге дә алардан тора бит. Беренче катта газ чыгып торып, икенче катта яшәүчеләр агуланырга мөмкин. Мондый хәлләрне булдырмый калу өчен, газчыларны өйгә кертергә, җиһазларга сакчыл карарга кирәк. Газ җиһазы да карап төзәтүгә мохтаҗ.

Алмаз Ханнанов әйтүенчә, кешеләр күңелсез хәлләргә газ җиһазларының дөрес эшләмәве түгел, аны куллана белмәү аркасында юлыга. Кулланучылар эшләп торган газ җиһазларын караучысыз калдыра, вентиляция, төтен юлларын үзгәртеп кора, үз белдеге белән газ җиһазларын алмаштыра икән.

– Газ казаны аша су җылытучылар (су җылыткыч куючылар) күбрәк агулана. Чөнки су җылыткычта ачык камера урнашкан. Ул бүлмәдәге бөтен һаваны үзенә суырып ала. Әгәр ул ябык камералы булса, һаваны тыштан алыр иде. Шуңа да мондый йортларда һава юллары ачык булырга тиеш. Су җылыткычның ябык камерасын алырга яки еш кына тәрәзәләрне ачып торырга киңәш итәбез, – ди ул. – Тәрәзәне ачкач, һава һәм төтен юлларында тарту көче бар икән, димәк, бирәдә куркыныч юк. Күп очракта тәрәзәне ачып торырга кирәк. Фатирда һава йөрергә тиеш.

Исегездә тотыгыз: «Йорт эчендәге һәм фатир эчендәге газ җиһазларыннан файдалануның һәм аларны карап тотуның куркынычсызлыгын тәэмин итү өлешендә газ куллану кагыйдәләре»нең (Россия Хөкүмәтенең 2013 елның 14 маендагы № 410 карары белән расланган) 10 нчы пункты нигезендә, газ җиһазларын алыштыруны фәкать махсуслашкан оешма гына башкарырга тиеш. Ул кулланучыларга техник хезмәт күрсәтүне бары тик килешү буенча алып бара.

«Газпром трансгаз Казан» сайтында газ казаннарына, плитәләргә техник хезмәт күрсәтүче оешмаларның тулы исемлеге бар. Кирәк кеше шунда кереп, яки үзләренә якын җирдә урнашкан кулланучыларга хезмәт күрсәтә торган бүлекчәгә килеп белешә ала. Бу оешмаларның лицензияләре бармы, хезмәткәрләре укытылганмы – барысын да тикшереп торалар.

ТӨП КАГЫЙДӘЛӘРНЕ ИСЕГЕЗДӘ ТОТЫГЫЗ!

- ✓ Газ җиһазлары төзек булсын.
- ✓ Газ плитәсе өстендәге һава торбасының вентиляция юлы ачык булсын.
- ✓ Газ баганасын томалап куймагыз. Белгечләр аны таба алмаса, газ чыгуны туктатып булмаячак.
- ✓ Төтен юллыгының чистарту уемнары тулган яки томаланган булмасын.
- ✓ Газ плитәсе яки казан урнаштырылган бүлмәдә йокламагыз.
- ✓ Газ җиһазларын үзегез урнаштырмагыз.

ӨЙДӘ ГАЗ ИСЕ КИЛСӘ...

- ✓ Кичекмәстән газ җиһазларын сүндерегез.
- ✓ Газ краннарын ябыгыз.
- ✓ Тәрәзәләрне ачыгыз.
- ✓ Фатирдан яки йорттан бөтен кеше чыгарга тиеш.
- ✓ Электр җиһазларына кагылмагыз. Утны сүндерергә, кабызырга, телефонны зарядкага куярга ярамый. Бинада тәмәке тарта күрмәгез!
- ✓ Кесә телефоныннан 04, 104 һәм 112 номерына шалтыратып, газ хезмәтен чакыртыгыз.

Сан

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан идарәсе мәгълүматлары буенча ел башыннан республикада сөрем газы белән агулануның **15** очрагы теркәлгән. Ике кеше үлгән, **31** кеше (шуларның **17**е – балалар) зыян күргән.

Сәламәтлек

Саклану артык булмас

Россиядә соңгы дүрт атна дәвамында COVID-19 белән чирләү очраклары арту күзәтелә. 2023 елның бишенче атнасында ил күләмендә 60 меңнән артык авыручы теркәлгән. Узган атнадан 33 процентка күбрәк күрсәткеч бу. Барлык очракларның 41 проценты Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Мәскәү өлкәсенә туры килә.

Роспотребнадзор белгечләре әйтүенчә, хәзерге көндә Россиядә өстенлек иткән коронавирус төрләре бик йогышлы санала. Әмма чир эләксә дә, җиңел формада уза, дип ышандыралар. Шуңа күрә дә өстәмә чикләү чараларын гамәлгә кертү турында сүз дә юк.

Коронавирус белән чирләүчеләрнең кисәк артуын ничек аңлатырга була соң? Биология фәннәре докторы Алексей Аграновский әйтүенчә, хәзер инфекция әлеге чир белән әлегәчә авырмаган һәм прививка кадатмаганнарны «аулый».

– Прививка кадатмаганнар эпидемиясе күзәтелә: иң авыр очраклар да, үлүчеләр дә шуларның өлешенә туры килә. Йогышлылыгы буенча коронавирусны кызамык йә чәчәк авыруы белән чагыштырырга була. Вирус – ул ялкын кебек, буш урыннарны яулап ала да, бер мизгелдә янгынга әйләнергә мөмкин. Вируска каршы торучанлыгы түбәнрәк булган кешеләр, коронавирусның хәзерге штаммнарын йоктырса, авырый башлаячак, – дип кисәтә белгеч.

Өстенлек иткән төрләрнең билгеләре нинди соң? Белгечләр, алар әллә ни үзгәрмәде, ди. Коронавирус йоктырган кешегә югары температура, баш авырту, хәлсезлек, томау төшү, ютәл, буыннар сызлау хас. Кайбер очракларда ашказаны-эчәк трактына бәйле борчулар да килеп чыгарга мөмкин.

Эпидемиологик вазгыять тотрыксыз чакта профилактика чараларына аеруча игътибарлы булырга кирәк. Битлек кию мәҗбүри саналмаса да, кешеләр күпләп йөри торган урыннарга битлектән бару зыян итмәс. Кулларны юып йөрү, антисептиклар куллану, бүлмәләрне җилләтү, дезинфекция кагыйдәләрен истә тоту да мөһим.

Санап киткән билгеләр күзәтелсә, өйгә табиб чакыртырга мөмкин. 65 яшьтән өлкәнрәкләргә, хроник авырулары булган кешеләргә яисә моңа кадәр коронавирус йоктырып авырганнар белән тыгыз элемтәдә булганнарга да, кисәк чирләп киткән очракта, медицина ярдәменә мөрәҗәгать итү мәҗбүри санала.

Төбәк	Хастаханәгә салынган	Сәламәтләнгән	Ачыкланган	Үлгән
Мәскәү	161	2320	2952	11
Санкт-Петербург	105	704	1224	7
Мәскәү өлкәсе	44	351	398	0
...				
Башкортстан	36	153	229	0
Краснодар крае	28	117	202	0
...				
Удмуртия	16	173	135	1
Татарстан	**47**	**12**	**89**	**0**
...				
Чукотка автономияле округы	0	12	11	0

Сүзгә-сүз

Анатолий АКСАКОВ, Дәүләт Думасының Финанс базары комитеты башлыгы:

Махсус хәрби операция барганда, күп кенә россиялеләр хәрби хәрәкәтләр зонасында катлаулы хәлгә эләккән гражданнарга яки хәрби хезмәткәрләргә ярдәм итүгә акча күчерүне сорап, телефон аша хәбәрләр ала. Мондый шалтыратуларга җавап бирергә кирәкми, чөнки бу – мошенниклар. Алар акча эшләп калырга тели.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – ЭЧКЕ ТУРИЗМ

Туроператорлар ассоциациясе мәгълүматларына таянып, илнең эчке туризмына бәйле саннар тәкъдим итәбез.

ИЛ ЭЧЕНДӘГЕ СӘЯХӘТЛӘР САНЫ (МЛН)

2021 ел >> **57 млн** / 2022 ел >> **61 млн**

Иң күп туристларны кабул иткән төбәкләр (млн)

Мәскәү өлкәсе – 22
Мәскәү – 18
Краснодар крае – 17
Санкт-Петербург – 8
Кырым – 6

Юллама көтелә

Россия Президенты Владимир Путин 21 февральдә Федераль Җыенга Юллама белән чыгыш ясаячак. Бу хакта ТАСС дәүләт башлыгы матбугат секретаре Дмитрий Песков сүзләренә таянып хәбәр итә. Чара «Гостиный двор»да үткәреләчәк.

Дмитрий Песков әйтүенчә, дәүләт башлыгы агымдагы вазгыятьне төп игътибар үзәгенә алачак. Шул ук вакытта Кремль вәкиле чарага чит ил журналистларының чакырылу-чакырылмау мәсьәләсенең әлегә хәл ителмәвен искәрткән.

Ял урыннары яңартыла

Татарстанның 48 шәһәр-районында 68 иҗтимагый киңлекне (парк, скверлар, яр буйлары, халыкның башка ял итү урыннары) төзекләндерү күздә тотыла. Шуның 8е – Бөтенроссия кече шәһәрләр бәйгесендә җиңүчеләр. Моның өчен федераль үзәк һәм төбәк бюджетыннан 2,9 миллиард сумнан артыграк акча биреләчәк.

«Татарстан шәһәрләрен үстерү институты» фонды җитәкчесе Наилә Зиннәтуллина әйтүенчә, республикада яшәүчеләр бигрәк тә Казанның ял итү урыннарының яңартылуын күптәннән зарыгып көтә. Әйтик, Горький паркы капкасын.

Кайбер паркларда бер сезонда төзекләндерү эшләренең берьюлы ике чираты башкарылачак икән. Мәсәлән, Алабуганың «Шишкин буасы» паркы, Лениногорск шәһәре Менделеев урамындагы буалар шарлавыгында спорт мәйданчыклары, Зәй шәһәре «Яшьләр» паркы шул рәвешле бик тиз төзекләндереләчәк. Аларда халык өчен кирәкле төрле мәйданчыклар булдырылачак. Бу эшләр Бөтенроссия кече шәһәрләр бәйгесе гранты һәм Татарстанның иҗтимагый киңлекләрен үстерү программасын гамәлгә ашыру өчен каралган акча хисабына башкарылачак.

Мошенникларга юл ябыла

1 марттан Дәүләт хезмәтләре порталына керү катлаулана. Моның өчен өстәмә ысул булдырыла. 1 июньнән аны куллану мәҗбүригә әйләнәчәк. Порталга керү өчен логин һәм пароль җыю белән берррәттән, әнә шул өстәмә ысулны да кулланачакбыз, дигән сүз. Бу порталдагы аккаунтларны мошенниклардан саклауны камилләштерү өчен кирәк.

Россиянең цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм мәгълүмат чаралары министры Мәксут Шадаев аңлатып үткәнчә, өстәмә ысул йә смс хәбәр, яисә тагын бер пароль кебек әйбер булачак. Шул рәвешле гади парольләр кулланучыларның (гадәттә аларның аккаунтлары еш кына вирус һөҗүмнәренә дучар була) интернеттагы иминлеген булдыру күздә тотыла.

Моңа кадәр Дәүләт Думасының Финанс базары комитеты рәисе Анатолий Аксаков яңа закон проекты эшләнелүе, аның нигезендә Дәүләт хезмәтләре порталы аша счетлардагы акчабызны күчерүгә үзебезнең үк тыю сала алачагыбыз турында белдергән иде. Депутат әйтүенчә, үзенә-үзе тыю салган кешенең счетыннан акча күчерелгән очракта, моның өчен тулысынча банк җавап бирәчәк.

Вакытлыча киметкәннәр

Якындагы айларда инфляция күрсәткече узган елның уңай нәтиҗәсе йогынтысында вакытлыча 4 проценттан кимрәк булачак. Ләкин күпмедер вакыттан соң инфляциянең бераз үсүе көтелә. Россия Үзәк банкы хәбәренә караганда, еллык инфляциянең 5–7% булуы, 2024 елда, 4 процентка кире кайтып, алга таба шул 4 процент чамасы тәшкил итүе күздә тотыла.

Исегезгә төшерәбез: Үзәк банк кичә төп ставканы 7,5% дәрәҗәсендә калдырды. Белгечләр билгеләп үткәнчә, инфляция үскән очракта, банк алдагы утырышларында төп ставканы берникадәр арттырырга мөмкин.

Һава үзгәрми

Татарстан Гидрометеоүзәге хәбәр иткәнчә, якшәмбе – 12 февральдә көндез аз гына кар-буран булачак. Һава температурасы алдагы көннәрдәге кебек: көндез термометрның терекөмеш баганасы –3…–8, төнлә –8…–13 градус күрсәтәчәк.

Синоптикларның башлангыч мәгълүматлары буенча, киләсе атна башы – 13–14 февральдә, циклон үтеп керү сәбәпле, урыны белән кар-буран, көчле җил көтелә. Һава температурасы үзгәрми диярлек.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Кесә телефоны: дусмы, дошманмы?

Һәрберебезнең кулында йә кесәсендә йөргән, смартфон дип аталган электрон җиһаз адәми затка файдагамы, әллә зыянгамы? Элегрәк язылган «Эчлек һәм тышлык» дигән мәкаләдә сорау башкачарак та куелган иде: «Гади кесә телефонын смартфон дәрәҗәсенә җиткергән инженерларга һәйкәл куясымы, әллә инде аларны суд каршына бастырасымы?» Ни хикмәт, ни гаҗизлек, сорауларның икесенә дә кистереп җавап бирү авыр.

Бу атнада гадәти булмаган халыкара дата – Дөньякүләм мобиль телефонсыз көн билгеләп үтелде. Янә сорау туа: телефоннан бер көнгә генә баш тартып торуда нинди хаҗәт, ни кирәклек бар? Кайда булсаң да, башны идереп, үзенә бактыра, туктаусыз ышкыта торган учка сыешлы ул нәмәрсәдән санаулы сәгатьләргә арынып тору ни бирә? Ихтимал, җанлы аралашу, кешенең янәшәлеген тоеп, бер-береңнең күзенә карап сөйләшүнең дә барлыгын, аның ихласрак икәнен, тәмен-рәхәтен искә төшерү өчен булса да кирәктер андый дата. Кешене табигый коммуникация, тере әңгәмәдән аеруда XXI гасыр хикмәтенең роле шактый зур бит. Шуңа да бүген ул җиһазның зыянлы якларын барлап чыгасы килгән иде.

Без ябышкан күптин-күп функцияле бүгенге мобиль телефон, үзебез бик сизмәсәк тә, безне дуслардан, туганнардан читләштермәгәндә дә ераклаштыра, шәхси кабырчыкка кертеп, изоляция тудырып кына калмый, дөньябызны да билгеле бер дәрәҗәдә виртуальләштерә, ясалма итә кебек. Кечкенә экран аша дөньяга чыгу, олы вә якты җиһанны бары шуның аша күрү, кайсы яктан гына карасаң да, дөрес түгел инде ул.

Онытмаган булсак, смартфон дигән җиһазга кадәр сатуга гади кесә телефоннары чыккан иде. Дистә, дистә ярым еллар халык шулардан файдаланды. Менә шул кимәлдә тукталып калган очракта, ягъни телефон смартфонга әверелмәгән тәкъдирдә, миңа калса, барысы да яхшы булачак иде. Мобиль элемтә – теләсә кайсы сәгатьтә, минутта башкалар белән сөйләшеп, хәл белешеп алу мөмкинлеге, сүз дә юк, кирәк, зарур. Балаң мәктәптән кайтып җиткәнме, туганың исән-сау, сәламәтме, күптән күрмәгән ахирәтең ни эшләр бетерә – сөйләш, чыбыклы телефонга әле кайчан барып җитәсең. Вакытында белеп, бәяләп, карар кылып тору өчен оператив мәгълүмат кеше өчен бик тә мөһим.

Тик менә фәнни прогресс дигәнең һич урынында тормый, файдагамы, зыянгамы, ул алга атлый. Гади дисплей урынына сенсорлы экран, мобиль интернет, видео төшерү, карау, алышу мөмкинлеге, геолокация, сәгатьләр буе уйналышлы кырык төрле интернет уеннар, теләсә кайчан, теләсә кайда «пәрәвез»гә керү, анда теләсә нәрсә карый алу, ялтыравык тормышны пропагандалаучы социаль челтәрләр – барысы да шул галәмәттә. Андый җайланма әллә адәми затның күзен кызыктырмый, яңалык, хикмәт яратучы яшь-җилкенчәкне әллә ымсындырмый, алар аңа әллә ябырылмый кала? Уйлап табучылардан бигрәк, җитештерүчеләр, сатучыларны инде әйткән дә юк, андый «уенчык»ка сорауның һуш китмәле буласын, әлбәттә, алдан ук белгән, чамалаган. Табышның да ишелеп киләсен сизеп эш иткән. Шундый шартларда смартфон ничек яралмасын, ничек таралмасын, ди.

Инженерларның, уйлап табучыларның төп гөнаһы биредә шул – мобиль телефон, нинди генә рәвешкә керсә дә, кулдан төшермичә, сәгатьләр буе үзенә бактыра торган җайланма булырга тиеш түгел иде. (Биредә әле мин радионурланыш, күзләр сәламәтлеге, телефонга бәйлелек сәбәпле туган психик тайпылышлар турында сүз алып бармыйм. Алары буенча тикшеренүләр әле башланып кына килә, диләр.) Аралашып, сөйләшеп алдың, хәл белештең дә кесәгә кире тыгып куйдың. Вәссәлам! Ярар, шунда ук калькуляторы, сәгате, будильнигы булсын ди. Калганы артык. Интернетка өйгә кайткач, компьютер аша кереп була. Мәктәп баласы очрагында әти-әни дә андый хәлләрдә «пәрәвез»дә утыруны чикли, аның вакытын билгели алыр иде. Шунда ук, кирәк икән, сурәт алышып, язышып та була.

Компьютерга бәйлелек, булган очракта да, смартфонга бәйлелектән ун тапкыр кайтыш, диләр. Компьютерны кесәдә йөртеп булмый ич. Урта яшькә җиткәннәрнең, өлкән буынның, бүгенге мобиль телефон дигәндә, ярый да «тормоз»лары бар. Бала-чага, үсмерләр, яшьләрдә тормоз әле формалашмаган, аларга кызык, әкәмәт күбрәк кирәк. Һәм алар аны, әллә кая барып йөрми генә, бүгенге шул телефонда таба. Телефонның кулдан төшмәве, аннан вакытлыча аерылып торуда олы фаҗига күрү, ягъни шул яссы хикмәткә бәйлелек – барысы да, аның артыкка киткән функция-кыланмышларында бит.

Әйткәнебезчә, җитештерүче, сатучы өчен бүгенге телефон файдагамы, зыянгамы – унынчы мәсьәлә. 140–150 миллион халык яшәгән Россиядә генә дә бүген ким дигәндә 100 миллион смартфон. Монысы – бер яктан. Икенче яктан, аны бер тапкыр алдың да гомер буе файдаланасың түгел. Һәркемнең кесәсендә йөргән ул «ышкыгыч» кешегә өч-дүрт елдан да артык хезмәт итмәслек итеп ясала. Ватылмаган очракта да син аны яңартырга мәҗбүрсең. Чөнки җитештерүчеләр аның яңа, тагын да купшырак, мөмкинлекләре артыграк булган модельләрен чыгарып тора. Алмый кара, дус-ишләрең үк: «Бу иске-москыңны ташла инде», – диячәк. Ул әйбер бүген гомумән ниндидер культ рәвешендә. Телефонсыз бала үзен иң кыерсытылган, иң фәкыйрь, иң бәхетсез бала итеп сизә. Балалык сәбәпле, ул нәмәрсә аны хәрәкәтле уеннардан аралап, ярым чирләшкә итәсен, дәресен әштер-өштер әзерләтәсен, күзләрен бозасын белми. Күпчелек бала-чаганың кулына аны, кешедән ким булмасын, дип, мәктәп яшенә җитүгә үк тоттыралар. Казынсын шунда көне буе. Яраганын да карасын, ярамаганын да. Ата-ананы гына борчымасын…

Ул электрон җиһазга дәгъва белдерүләрдә, бәлки, сугышып туктагач, йодрык уйнату кебек, әллә ни мәгънә дә юктыр. Смартфонны кулланыштан хәзер инде беркем дә кысрыклап чыгара алмый. Ул барыбызның да кулында, кесәсендә – җыеп алырмын димә. Бүгенге телефоннарда кулланылган электрон технологияләр авторы, ярымүткәргечләр буенча олы белгеч, Нобель премияле академик Жорес Алферов та, хәзерге хәлләрне күреп, каберендә әйләнә-әйләнә инде бәлки арыгандыр. Бер уйлаганда, кызык һәм кызганыч та инде – башта дусмы, дошманмы икәнен ачыкламыйча «өләшеп» чыгалар да, соңыннан елына бер көн генә булса да аны кулга алмаска өндәп, халыкара датаны гамәлгә куялар. Андый көннең барлыгын ваемсыз халык юньләп белмәсә, белгәннәрнең исе китмәсә дә.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

tatarstan.ru

ЭШЛӘГӘНГӘ ЭШ БЕТМИ

Балаларга – бакча, җитәкчеләргә – бәя. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов эш сәфәре белән Әлмәттә булды. Сабыйлардан сөенче алып, ул яңа балалар бакчасы ачты, аннан район җитәкчесенең узган елга хисабын тыңлады.

«Алсу»лы булдылар

Әлмәт балалары хәзер яңа бакчага йөриячәк. Рәис Рөстәм Миңнеханов катнашында биредә яңа мәктәпкәчә белем бирү бинасын ачтылар. Бакча 110 урынга исәпләнгән. «Алсу» микрорайонында сафка басканга, бакчага исемне дә «Алсу» дип кушканнар. Бинада музыка, физкультура залы, психологик кабинет, татар һәм инглиз телләре бүлмәсе, медицина блогы урнашкан. Территориясендә 5 уен мәйданчыгы булдырылган.

– Бу – балалар һәм ата-аналар өчен аеруча күтәрелгән вакыйга. Котлыйм сезне! Балаларны тиешенчә тәрбияләү өчен шартлар тудыра алуыбызга сөенәм. Бу – безнең эшебезнең үзгәрешсез кала торган бер юнәлеше, – диде Рөстәм Миңнеханов.

«Алсу» микрорайонына балалар бакчасы, чынлап та, бик кирәк булган. Монда яшәүчеләр саны 15 меңгә җиткән икән инде. Яшь гаиләләр күплеге белән дә аерылып торган район ул.

Әлмәт районы башлыгы Тимур Нагуманов балалар бакчасы өчен Рөстәм Миңнехановка рәхмәт сүзләре җиткерде.

– Без бу хакта күптән хыяллана идек. Микрорайонда яшәүче әниләрдән дә күп мөрәҗәгатьләр булды. Биредә яңа «Адымнар» мәктәбен дә ачтык. Моның өчен бик зур рәхмәт! Балаларга искиткеч шартлар тудырылган, – диде җитәкче.

Елга нәтиҗә

Әлмәт районы башлыгы Рөстәм Миңнехановка узган елгы нәтиҗәләр һәм бу елга куелган бурычлар турында да сөйләде.

Рәис Рөстәм Миңнеханов Әлмәтнең Татарстан районнары арасында аерым статуска ия булуын ассызыклады.

– 213 меңнән артык кеше яшәгән, республиканың көньяк-көнчыгышы өчен тарту көченә ия булган зур муниципалитетларыбызның берсе ул. Биредә «Татнефть»нең төп бүлекләре эшли. Республиканың иң зур нефть компаниясенең эшчәнлеге ничә еллар дәвамында Татарстанда яшәүчеләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән. Алар барлык проектларда да катнаша, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан җитәкчесе әйтүенчә, Әлмәтнең потенциалы зур. Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, районның мөмкинлекләре авыл хуҗалыгы өлкәсендә тулысынча ачылмаган әле. Сүз уңаеннан, ел йомгаклары буенча агросәнәгать комплексы рейтингында Әлмәт районы 39 нчы урынны гына били. Терлекчелек өлкәсендә уңай үзгәрешләр булган.

Рәис әйтүенчә, Әлмәттә төзелеш эшләре дә күп башкарылган. Әйтик, «Безнең ишегалды» проекты кысасында районда 78 ишегалдына ремонт кергән. Шәле – Баулы автоюлының Алексеевск – Әлмәт өлеше буенча да эш алып барыла.

Хәл ителергә тиешле җитди бурычларның берсе – җәмәгать транспортын үстерү. Кызганыч, соңгы елларда Әлмәт өчен бу «авырткан җир» санала. Биредә яшәүчеләрнең канәгатьсезлеге җәмәгать транспорты маршрутлары һәм транспорт җитмәүгә бәйле. Бу җәһәттән Тимур Нагумановка эшне тиешенчә оештырырга кушылды.

Торак-коммуналь хуҗалыкка бәйле сораулар да шактый. Әлмәт җитәкчелеге исеменә җәмәгать урыннарын чиста тотмау, юлларны кар һәм боздан арындыру, җылылык һәм суга бәйле мөрәҗәгатьләр еш килә икән.

Рөстәм Миңнеханов аерым тукталган тагын бер мәсьәлә – яшьләр белән эшләү. Биналар төзү генә түгел, аларны тиешле эчтәлек һәм кешеләр белән тутыру да мөһим бит әле. «Яшьләрне үз илләренең, республиканың һәм кече ватаннарының патриотлары итеп үстерү бик мөһим», – диде Рәис.

Сан

➢Әлмәт районында 2022 ел нәтиҗәләре буенча уртача хезмәт хакы 2021 ел белән чагыштырганда 18,9 процентка арткан һәм 63,8 мең сумга җиткән.

➢2022 елда эшсезлек дәрәҗәсе 0,64 проценттан 0,15 процентка кадәр кимегән.

➢Әлмәт кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә эшләүчеләр саны буенча – 18 нче урында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны буенча – 12 нче урында.

Без беренче унлыкта!

Мәскәү Кремлендә ил төбәкләре арасында төзелгән тормыш сыйфаты рейтингын игълан иттеләр. Илбашы Владимир Путин алдынгылар рәтендә баручы Татарстанны мактады. Үзәккә кадрлар «үстергәне» өчен республика җитәкчесе Рөстәм Миңнехановка рәхмәт тә әйтте.

Татарстан Рәисе Стратегик инициативалар агентлыгының күзәтүчеләр советы утырышында катнашты. Билгеле булганча, 2011 елда барлыкка килгән әлеге оешма тормыш сыйфатын яхшырту, белем бирү, кадрлар әзерләү, төбәк һәм шәһәрләр үсеше, экология, яңа технологияләр уйлап табуга бәйле проектларга ярдәм күрсәтә. Ел йомгаклары буенча, белгечләр тормыш сыйфаты рейтингын да төзи. Тикшерү барышында медицина, торак белән тәэмин итү, чисталык, иминлек, дәүләт хезмәтләре кебек 141 күрсәткечне исәпкә алалар. Озын сүзнең кыскасы: Татарстанда тормыш шәп! Республика әлеге рейтингның алтынчы баскычында. Без Мәскәү, Санкт-Петербург кебек зур шәһәрләргә, Төмән өлкәсе, Ямал-Ненец, Ханты-Манси автономияле округлары кебек нефть һәм газ төбәкләренә генә уздырган.

Рейтинг кысасында Татарстанда алып барылган эш турында Илбашына Рөстәм Миңнеханов сөйләде.

– Республикада тормышка ашырылучы барлык чаралар халыкның гомер озынлыгын арттыруга юнәлдерелгән, – диде Татарстан Рәисе. – Узган ел нәтиҗәләре буенча, республикада яшәүчеләрнең гомер озынлыгы өч елдан артыкка үсте һәм 74,58 ел тәшкил итте.

Аның фикеренчә, тормыш сыйфаты рейтингы «авырткан җир»ләрне ачыкларга һәм агентлык ярдәмендә аларны чишү юлларын эзләргә ярдәм итә. Мәсәлән, агентлыкның «Смартека» платформасы гамәлдә. Биредә төбәкләр үрнәк тәҗрибә белән уртаклаша. Татарстан әлеге мәйданда күреп, башка төбәкләрдәге җиде тәҗрибәне үзендә файдалана башлаган. Үзе исә ун үрнәк эш белән уртаклашкан, хәзер алар илнең 14 төбәгендә кулланыла да инде. Аерым алганда, Рөстәм Миңнеханов йөкле хатын-кызларның сәламәтлеген ачыкларга ярдәм итүче «Элемтә» проектын телгә алды. Бүген республика тәҗрибәсен Ингушетия һәм Ненец автономияле округында да файдаланалар.

– Әлеге системаны гамәлгә кертү йөклелек вакытында килеп чыгарга мөмкин булган куркынычларны алдан кисәтергә, шул рәвешле 16 мең хатын-кыз һәм аларның балаларының тормышын саклап калырга ярдәм итте, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Республикадагы тагын бер уңай тәҗрибә – Талантлар университеты. Республика башлыгы сәләтле яшьләрне барлау эше турында сөйләде. Былтыр, мәсәлән, Татарстан мәктәпләрендә белем алучы 237 укучы илкүләм олимпиадаларда җиңгән һәм призлы урыннар яулаган. Әлеге күрсәткеч буенча без ил төбәкләре арасында өченче урында.

– Бүген бу тәҗрибә илнең биш төбәгендә кулланыла инде, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Соңгы ун елда республикада 40 мең сабыйга 253 балалар бакчасы, 48 мең укучыга 76 мәктәп төзелүен дә әйтте Рәис. Быел Татарстанда 4 бакча һәм 11 мәктәп сафка басачак дип көтелә.

– Федераль ярдәм белән әлеге белем бирү йортлары заманча итеп җиһазландырыла һәм алар барлык таләпләргә җавап бирә, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ул дәүләт башлыгына төзелеш тармагына даими булышып торулары һәм ташламалы ипотеканы дәвам иттерүләре өчен рәхмәт тә әйтте. Моның нәтиҗәсе буларак, Татарстанда тарихта тәүге тапкыр 3 миллион квадрат метрдан да күбрәк торак төзеделәр. Рөстәм Миңнеханов әлеге күрсәткечне алга таба да киметмәскә, шәһәрләрдә генә түгел, авыл җирлекләрендә дә төзергә җыенуларын итте. Аның фикеренчә, йортлар салып кына эш бетми, әлеге җирлектә яшәүчеләр белән бергә тирә-юньне төзекләндерү дә мөһим. Бу хакта сөйләгәндә республикада 2019 елдан бирле гамәлдә булган «Безнең ишегалды» проектын телгә алды ул. Аның кысасында республикада 3,3 меңнән артык ишегалдын рәткә китергәннәр.

– Татарстан ил үсешенә зур өлеш кертә, – диде Владимир Путин. – Төзелеш тармагын алсак, сез үз күрсәткечләрегез ярдәмендә илкүләм саннарны да үстерәсез. Бигрәк тә шуны әйтәсем килә: Татарстаннан чыккан белгечләр узган ел торак төзелеше тармагында бик зур уңышка иреште. Бу – яңа тарихта рекорд күрсәткечләр. Хәер, совет чорында да Россиядә бу кадәр төземәгәннәр бугай. Шуңа күрә сезгә федераль дәрәҗәгә илкүләм бурычларны хәл итүче кадрлар әзерләгән өчен рәхмәт әйтәсем килә. Татарстан бу юнәлештә бик яхшы үрнәк.

Республиканың элеккеге төзелеш министрлары, хәзерге вакытта Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин һәм Россия төзелеш министры Ирек Фәйзуллинга хөрмәт белдерүе, күрәсең.

Тормыш сыйфаты рейтингы

1	Мәскәү	11	Мәскәү өлкәсе
2	Санкт-Петербург	12	Севастополь
3	Төмән өлкәсе	13	Пенза өлкәсе
4	Ямал-Ненец автономияле округы	14	Свердловск өлкәсе
5	Ханты-Манси автономияле округы	15	Чиләбе өлкәсе
6	Татарстан Республикасы	16	Чувашия Республикасы
7	Белгород өлкәсе	17	Түбән Новгород өлкәсе
8	Чечня Республикасы	18	Сахалин өлкәсе
9	Тула өлкәсе	19	Самара өлкәсе
10	Калининград өлкәсе	20	Камчатка крае

** (2021 ел нәтиҗәләре буенча)*

«ТӘГӘРМӘЧЛЕ КИБЕТ»ЛӘР

Кибете булмаган авылларга йөри торган автолавкаларның товар әйләнешен арттырырга, халыктан тире, сөт, яшелчә һәм җиләк-җимеш җыюга зуррак игътибар бирергә кирәк. Татарстан кулланучылар җәмгыятьләре һәм кооператив вәкилләренең 2018–2022 ел нәтиҗәләре буенча XX гомуми отчет-сайлау җыелышында киләсе елларга әнә шундый бурычлар куелды.

vk.com

Халкы аз булган һәм үзәктән читтәрәк урнашкан авылларны азык-төлек белән тәэмин итү Татарстан кулланучылар җәмгыятенең төп бурычы булып тора. Әлеге мәсьәләгә республиканың авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров аерым тукталды. Татарстанда 3073 авыл бар. Аларның 1148енә «тәгәрмәчле кибет»ләр йөри. Бу уңайдан Марат Җәббаров кулланучылар кооперациясе эше буенча Биектау һәм Алабуга районнары җитәкчеләренә шелтә белдерде.

– Биектау районында кооператив эшчәнлегенең гомуми күләме биш ел дәвамында – 56, Алабуга районында 51 процентка кимеде. Сез бу юнәлештә җитәрлек эшләмисез дип уйлыйм. Тагын бер тапкыр әлеге мәсьәләне җитди контрольгә алуыгызны сорыйм, – диде ул.

Шул ук вакытта министр Кукмара һәм Әлки районнарын үрнәк буларак китерде. Аның сүзләренчә, соңгы өч елда Кукмара районы кулланучылар кооперативы үз тармакларын үстерүгә – 150 млн сумнан артык, ә Әлки районы 148 млн сум керткән. Марат Җәббаров кооператив җитәкчеләренә халык аз яши торган авылларда автокибетләр системасын җайга салырга кушты. Бу мәсьәләдә өч районны билгеләп узды. Әйтик, Менделеевскида «тәгәрмәчле кибет»ләрнең айлык товар әйләнеше – 70 мең, Лениногорскида – 86 мең, Аксубайда 112 меңнән дә артмый. Ә бу санны, министр әйтүенчә, ким дигәндә 250 меңгә кадәр җиткерергә кирәк. Кулланучылар берлеге рәисе Рашат Шәймарданов биш ел эчендә 260 млн сумнан артык товар сатучыларны әйтеп узды. Алар – Мамадыш, Алексеевск, Балык Бистәсе һәм Тәтеш райполары.

Халыкка тәкъдим ителә торган товарларның аз ассортиментта булуы, кешеләрнең кереме аз, хезмәт күрсәтелә торган авылларда халык саны аз булу. Автокибетләрнең товар әйләнеше түбән булуның сәбәпләрен әнә шулай дип билгеләп уздылар. Шулай ук авылда яшәүчеләрнең транспорты һәм район үзәкләренә, башка авылларга барып йөрү мөмкинлеге булу да автокибетләргә булган ихтыяҗны киметә.

– Аларның эш графиклары сездән раслана, эш үтәлешен катгый контрольдә тотарга кирәк, – дип мөрәҗәгать итте бу уңайдан Марат Җәббаров район башлыклары һәм башкарма комитет җитәкчеләренә. – Әгәр дә сез автокибетләрне нәтиҗәле куллануны оештыра алмыйсыз икән, димәк, алар сезгә кирәк түгел.

Кулланучылар җәмгыяте шөгыльләнә торган тагын бер юнәлеш – халыктан һәр төрле продукция җыю. Рашат Шәймарданов әйтүенчә, авырлыкларга карамастан, биш ел эчендә хәзерләү әйләнеше 1,7 тапкыр арткан. Ягъни һәр хуҗалыктан авыл хуҗалыгы һәм чимал җыю 39 мең сумнан арткан. Иң зур күрсәткечкә баулылар ирешкән. Ә менә Түбән Кама, Менделеевск, Алабуга һәм Балтач районнарында бу эшләр бик акрын бара.

– Авыл халкы бездән тагын да зуррак активлык көтә, – диде Кулланучылар берлеге рәисе. – Һәр гаилә үзеннән арткан продукцияне сатып, бераз акча эшләргә тели. Безнең бурыч – аларга мондый мөмкинлек тудыру.

Кулланучылар җәмгыяте халыктан йон, тире, сөт, дару үләннәре җыю, бәрәңге һәм яшелчәләр сатып алу белән шөгыльләнә. Шулай итеп, биш ел эчендә халыктан бәрәңгене – 2,1, йонны – ике тапкыр, макулатураны – 173, тирене 160 процентка арттырып җыйганнар. Әйтик, узган ел 14928 центнер йон, 6795 тонна бәрәңге, 5061 тонна яшелчә җыеп алынган. Кооперативларда колбаса продукциясен әзерләү – 192, балык – 80, кондитер эшләнмәләре әзерләү 57 процентка арткан. Ә менә сөт, җиләк-җимеш җыю буенча эшләр әкрен бара, дару үләннәре әзерләү буенча бөтенләй бер урында гына таптаналар. Бәрәңге һәм яшелчәләр җыю буенча Әлки кооперативын мисалга китерделәр. Аларны халык белән кулга-кул тотынышып эшләү үрнәге буларак күрсәттеләр.

– Бу – сезнең төп бурычыгыз, – дип мөрәҗәгать итте бу юлы да район башлыкларына Марат Җәббаров. – Моның өчен республика барлык шартларны да тудыра. Ел саен республика хөкүмәте тармак өчен 30 млн сум субсидия бирә. Бәрәңге һәм яшелчәләр хәзерләү буенча кулланучылар җәмгыяте халыкны үз продукциябез белән тулысынча тәэмин итә ала, дип саныйм. Без авыл халкына үз продукциясен сату, акча эшләү өчен шартлар тудырырга тиеш. Ә шәһәрдә яшәүчеләр арадашчыларның озын чылбыры аша узмыйча гына сыйфатлы ризыклар сатып алырлык булсын иде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ИСТӘ, ҺАМАН ДА ИСТӘ

«ЭШ» 1918–1920 | «ТАТАРСТАН ХӘБӘРЛӘРЕ» 1920–1922 | «ТАТАРСТАН» 1922–1924 | «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» 1924–1951

«ВТ» – 105 12 март 2023

1951–1960 «СОВЕТ ТАТАРСТАНЫ» | 1960–1992 «СОЦИАЛИСТИК ТАТАРСТАН» | 1992– «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

«Ватаным Татарстан» газетасының 105 еллык юбилее елында, ягъни быел минем әтием һәм әниемнең тууларына 100 ел тула. Аларның тормышлары, эшчәнлекләре газета тарихына тыгыз бәйләнгән, тәгаен әйткәндә – аның «Кызыл Татарстан», «Совет Татарстаны», «Социалистик Татарстан» исеме белән чыккан чорына.

Бөек Октябрь революциясенең 38 еллыгына багышланган бәйрәм демонстрациясе (1955 ел). Беренче рәттә алгы планда – шагыйрь Мөхәммәт Садрый (ул вакытта «Совет Татарстаны» газетасында әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире), аннан уңда – Мәдинә Мөхәммәдьярова, аның артында – шагыйрь Мәхмүт Хөсәен. Кулына флажок тоткан бала – язма авторы.

Әтием Мостафин Мөдәррис Мөҗип улы 1941 елда 18 яшьтә Мөслим район газетасында эшли башлый. 45 еллык журналистлык гомерендә аңа төрле матбугат органнарында эшләргә туры килә, 1952–1953 елларда Чистайда «Сталин байрагы» өлкә газетасы мөхәррире була, ләкин эшчәнлегенең төп өлеше «Ватаным Татарстан»га бәйле. Ул очерк язу остасы иде (ул чорда газетада хезмәт кешеләре турында очерклар даими языла торды), армый-талмый республика районнарына командировкага йөрде, бигрәк тә авыл хуҗалыгына бәйле күп кешеләрне яхшы белә иде.

Әнием Мөхәммәдьярова Мәдинә Нәҗип кызы эшен Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында корректор булып башлый, ә сугыштан соңгы елларда, пенсиягә чыкканчы газетада (заманында төрле исемнәр белән нәшер ителгән хәзерге «ВТ»ны күздә тотам) өлкән корректор, тәрҗемәче һәм унсигез ел дәвамында җаваплы секретарь урынбасары вазыйфаларын башкарды. Ул елларда газета макетын эшләгәндә төп корал – карандаш һәм линейка, калганы – интуиция һәм осталык, өстәвенә редакция белән типография арасында бертуктаусыз йөрү.

Тулаем алганда, әтием-әнием язмышы турында уйланганда, яшьтән үк аларга җитди авырлыклар очравына карамастан, тормышлары бәхетле икәнен һәм анда газета эше мөһим урын алып торуын күрәм. Әмма газета юбилее алдыннан мин алар турында түгел (рәхмәт, әтием-әнием турында мәкаләләр газетада да, юбилей китапларында да чыкты), ә бәлки балачактан, ягъни 1950 нче еллардан бирле истә калган редакция тормышының кайбер күренешләре турында язып үтәсем килә.

Бәлки, безнең яшәү урыны Матбугат йортына якын, ә без укырга кергән 39 нчы мәктәп 5 минутлык арада булгангадыр, мин әти-әниемнең эшләгән җирендә еш булдым. Һәрхәлдә Бауман урамының 19 нчы йортында урнашкан Матбугат йорты хәтердә аерым бер галәм булып саклана. Казан үзәгендәге республиканың төп басмалары редакцияләре һәм матбугат комбинаты өчен 1930 елларда махсус салынган искиткеч бу бинада хәзер люкслы «Ногай» кунакханәсе урнашкан. Әмма миңа, элеккечә ишекне ачып, киң баскычтан безнең редакция урнашкан өченче катка менеп китсәм, анда кайбер язучылар (шул ук бинада Язучылар берлеге урнашкан, редакцияләрдә эшләүче язучылар да бар иде), ә редакциянең үзендә аның хезмәткәрләре очрар кебек. Мин аларның күбесен, курьерлардан һәм китапханәчедән башлап (редакциянең шул ук катта үз китапханәсе бар иде) бик яхшы хәтерлим. Мине ничектер үз итәләр, якты чырай белән каршы алалар иде…

Матбугат йортының икенче катында – шулай ук редакцияләр, дүртенче катта – Татарстан китап нәшрияты, бишенчедә – данлы Тукай клубы, икенче һәм дүртенче катларда – буфет, анда әти-әни белән керү – үзе бер күңеллелек. Ул вакытта Матбугат йортында ашханә юк иде, соңрак өченче каттан типография белән уртак ашханәгә керү юлы ачтылар.

1950 нче елларда газета мөхәррире Галим абый Рябков була. Кайсы еллардан бирледер, төгәл белмим, әмма шундый гадәт урнашкан иде: 1 гыйнварда көндез редакция хезмәткәрләре балалары белән Яңа ел бәйрәменә җыела. Гыйнвар башында бер атналык ялга күнеккән хәзерге укучыга моңа ышану кыендыр да: 1 гыйнвар бердәнбер ял көне иде (31 декабрь һәм 2 гыйнвар – эш көннәре). Бу әле телевидениесез һәм Яңа елда телевизорга ябышып утырусыз тормыш иде. Бүлмәләрнең берсендә – түшәмгә җиткән, матур итеп бизәлгән чыршы. Матур киенеп, җыелышып күңел ачу – бу ниндидер күңел күтәренкелеге билгесе түгелме? Соңрак чыршы бәйрәмен Тукай клубында үткәрә башладылар.

Шул катлаулы һәм бик үк тук булмаган елларның энтузиазмын күрсәтүче тагын бер күренеш – бәйрәм демонстрацияләре, алардан башка да бәйрәмне күз алдына китереп булмый. Матбугат йорты янына җыелып, гармунга кушылып җырлап-бию, аннары Бауман урамыннан Ирек мәйданына хәтле күтәрелү… Күпләр, шулай ук балалар белән.

Мәктәп яшенә җитүгә, чыршы бәйрәмендә очраша торган «редакция балалары»ннан күпләребез Васильево бистәсенә урнашкан Муса Җәлил исемендәге пионер лагерена бара башладык. Ул заманда барыбыз да диярлек коммуналкада яшибез, бакча санаулы кешедә генә, ә профсоюз бирә торган юлламалар үзе бер зур ярдәм иде. Ял көннәрендә, гадәттәгечә, әти-әниләр килә, лагерь янындагы урманда ял итәбез. Кызганыч, безнең буын «редакция балалары»ның кайберләре дөнья куйды инде.

Узган гасырның алтмышынчы елларында редакция тормышының кайбер хатирәләрне янә искә төшерим әле: шул ук өченче катта мәдәният эшлеклеләре, артистлар белән очрашулар гына түгел, ә авторларның яңа язган җырларын редакциягә килеп башкару гадәте бар иде. Бер бүлмәдә җыелып, җырны тыңлап, фикер алышу була иде. Шуларның берсе – популяр җырлар авторы Фәтхерахман Әхмәдиев белән очрашу истә калды.

Журналистлар берлеге рәисе Ш.Х. Хамматов булгач, Тукай клубында СССР күләмендә данлы шәхесләр белән очрашулар еш үткәрелде. Ул вакытның иң зур геройлары, билгеле, космонавтлар иде. 1966 елның мартында очучы-космонавт Валентина Терешкова һәм легендар очучы Советлар Союзы Герое Георгий Мосолов белән очрашуда Тукай клубы шыгрым тулы иде.

Якынча шул ук елларда СССРда «производственная гимнастика» дигән чара кертелде. Безнең өченче катта да көндезге 11 сәгатьтә хезмәткәрләр, бүлмәләрдән чыгып, озын коридорга тезелеп, радиодан яңгыраган боерыклар һәм музыкага кушылып күнекмәләр ясалды.

Бергәләшеп гөмбәгә барулар оештырыла иде. Шул ук елларда Казанга ук терәлеп торучы Займищеда бакчалы да булдык. Буп-буш ташландык кыр иде ул. Менә шунда йортлар салынды, агачлар баш калкытты. Бакча ширкәтенең бер өлешендә нигездә «Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татария» газеталары хезмәткәрләре – (редакторлардан башлап техник секретарьларга хәтле), аннан бер төркем язучылар, үзәк газеталар хәбәрчеләре участоклы булды. Гөлсем апа Халитова, Степан абый Дементьев, Нәкыя апа Вәлиева, Диләфрүз апа Мәгъсумова безнең бакча күршеләре иде. Кичләрен төп аллея авыл урамын хәтерләтте, балалар үзара аралашып үсте. Вакыт уза, бакчаларның шактый өлешен яңа хуҗалар сатып алды, ләкин исеме элеккечә – СНТ «Журналист».

Тормыш булгач, төрле хәлләр булгандыр, әмма шунысы бәхәссез: ул заман кешеләре бер-берсенең шатлыкларын да, кайгыларын да уртаклашып, бердәм гаилә булып яшәде. Гомер узган саен уй-фикерләрдә менә шушы хакыйкать өстенлек итә.

Гөлшат МОСТАФИНА,
Казан федераль университеты доценты

КАБАТЛАНМАС БАТЫРЛЫК

1943 ЕЛНЫҢ 8 ФЕВРАЛЕНДӘ СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ МИХАИЛ ДЕВЯТАЕВ, ДОШМАН САМОЛЕТЫ ШТУРВАЛЫ АРТЫНА УТЫРЫП, БЕР ТӨРКЕМ ИПТӘШЛӘРЕ БЕЛӘН ӘСИРЛЕКТӘН КАЧА

Советлар Союзы Герое Михаил Девятаевны без әле үзе исән чагында ук легенда буларак кабул иттек. Чыннан да, аның батырлыгын беркем дә кабатламый. Исеме буыннан буынга онытылмасын өчен, Герой хакында истәлекләр дә шактый. Туган җире – Мордовия Республикасының Торбеево авылында аңа багышлап музей ачылган, 14 документаль, бер нәфис фильм төшерелгән. Төрле илләрдә, Россия шәһәрләрендә һәйкәлләр дә куелган, китаплар да язылган, үзе дә истәлекләрен барлап калдырган.

Күктән төшкән бәхет

Герой белән танышуым да, күрешүем дә көтмәгәндә булган иде. Бишенчегә күчкәч, безнең сыйныфны Арча педучилищесын тәмамлап кайткан Земфира апа Кәримова кабул итеп алды. Отряд исеме дә яңа буласы икән – Советлар Союзы Герое Михаил Девятаев. Хәтерем ялгышмаса, аңа кадәр бу исемне әллә ни ишеткән юк иде кебек, дәррәү кубып, тәрҗемәи хәлен, нинди батырлык кылуларын өйрәнергә тотындык. Геройга багышлап отряд сборлары оештырдык, чыгышлар ясадык. «Девятай» дип аталган яңа җыр өйрәндек. Ә үзе белән университетның беренче курсында укыганда, Аксубай районының Шәрбән авылында күрештек. Анда безне укырга килгәч тә, бәрәңге җыярга җибәргәннәр иде. Рус филологлары да шушы авылда. Беренче көнне үк Шәрбән егетләре шәһәрдә туып үскән кәттә кызларга «бәйләнгән» булып чыкты. Алар арасында Михаил Девятаев кызы да бар икән. Икенче көнне үк Шәрбәнгә әтисе килеп төште. Безнең, журналист булам дип, зур хыяллар белән янып йөргән чак бит инде, мондый мөмкинлекне һич тә кулдан ычкындырасы түгел. Егетләр шундук кыска гына очрашу оештырдылар.

Берничә ел элек геройның улы Александр Михайлович белән күрешкәч, мин аның әтисе язмышына кагылышлы тагын бик күп вакыйгалар турында ишеттем. Ул очрашу да без җырлап үскән «Девятай» җырына бәйле иде. Җырга көйне Сара апа Садыйкова язган. Композиторның кызы Әлфия Айдарская аны архивтан табып алып, дөньяга чыгарырга теләде, шул җәһәттән Александр Михайлович белән дә очрашу оештырган иде.

Гаиләдә 13 нче бала булып туган Михаил Девятаевның Казандагы тормышы 1934 елда башлана. 17 яшьлек егет басуда башак ашаганда тотыла да, аңа беркетмә төзиләр. Ул, җинаять эше ачылудан куркып, документсыз-нисез, яланаяк Казанга чыгып китә.
1940 елда Михаил Девятаев Ворошилов исемендәге Беренче Чкалов хәрби авиация училищесын тәмамлый. 1941 елның 22 июнендә ул хәрәкәттәге армиядә була. Өченче көндә үк Минск янында фашист «Юнкерс»ын бәреп төшерә. 1941 елның 16 сентябренә кадәр 22 яшьлек очучы дошманның 9 самолетын юк итә. Аның исәбендә 180 хәрби очыш була. 1944 елның 14 июлендә ул унынчы дошман самолетын юкка чыгара һәм үзе дә әсирлеккә эләгә.



Әсирлектә

Дошман утка тоткан очкычтан Девятаев парашютта сикерә. Сикергән вакытта башы белән стабилизаторга килеп бәрелә. Җиргә төшкәндә ул аңсыз була. Аны әсирлеккә алалар. Александр Михайлович әйтүенчә, шушы халәте аны ул чактагы репрессиядән коткара да инде. Чөнки сугыш вакытындагы законнар буенча, совет очучыларына әсирлеккә төшәргә ярамый, алар үзләрен атып үтерергә тиеш булалар. Шул максаттан яннарында һәрвакыт корал йөртәләр. Ә монда очучы аңын югалткан була. Димәк, инструкция бозылмый.

Девятаев берничә концлагерьда була. 1944 елның 13 августында качып та карый, әмма аны тоталар, шул сәбәпле Заксенхаузен дип аталган үлем лагерена җибәрәләр. Бәлки бу җәза тормышка да ашырылыр иде. Шунда лагерьның чәч алучысы (элеккеге совет танкисты, офицер) Девятаевның киемендәге язуны штрафник, бер көн элек кенә вафат булган Степан Никитенконыкына алыштырып куя. Статусын үзгәртү Девятаевны үлем җәзасыннан коткара. Шушы исем белән аны Узедом лагерена озаталар. 1945 елның 8 февралендә, үзе белән тагын ун әсирне алып, Девятаев дошман бомбардировщигында һавага күтәрелә…

Заксенхаузенда – икенче тапкыр

Сугыш чоры законнары буенча, әсирлектә булган һәр хәрби кеше фильтрация лагерена эләгә. Анда аны һәрьяклап НКВД вәкилләре тикшерә. Шул сәбәпле, Михаил Девятаев кабат Заксенхаузен лагерена килеп эләгә. Аерма шунда: бу юлы инде аны совет конвоирлары саклый. Фильтрация лагеренда Девятаевны 8 ай тикшерәләр. Очучы хыянәтче түгелме? Немец бомбардировщигын, чыннан да, үз теләге белән алып киткәнме? Немецлар мәҗбүр итмәгәннәрме? Мондый шикләнүләр Девятаевны әле 12 ел дәвамында озатып бара.

Югыйсә Девятаев Пенемюндедагы ракеталар җыю үзәгеннән яшерен документларны да кулга төшереп кайткан була. Бу да ярдәм итми, күрәсең. Аны запаска 1945 елның ноябрендә җибәрәләр. Очучы башта гаиләсенә: «Мин әсирлектән кайтам. Кабул итәсезме?» – дигән хәбәр җибәрә. Белүебезчә, ул чорда әсирлектән кайтучылар белән әллә ни санлашып тормыйлар. Әмма Моратовлар кияүләренә сүз әйтмиләр. Девятаев озак вакыт эшкә урнаша алмый йөри, хәтта шул дәрәҗәгә җитә ки, аны эшсез йөргәне өчен утыртмакчы да булалар. Беркемнең дә элеккеге әсир белән бәйләнәсе килми. Куркалар, чөнки илдә репрессия хакимлек итә. Александрның әтисе ул вакытта хәтта каршыга килгән таныш-белешләренең дә юлның икенче ягына чыгып китүләре, күрмәмешкә салышулары турында сөйли. Шулай да аны тора-бара Елга портына вокзал буенча кизү торучы итеп алалар, аннан ул катерда капитан-механик булып эшли башлый.

Үзгәреш

1956 елда Девятаевлар гаиләсендәге хәлләр тамырдан үзгәрә. Шул елларда Никита Хрущев теге яки бу сәбәп белән онытылып калган геройларны эзләргә дигән боерык чыгара. «Красная Татария» журналисты Ян Винецкий, шул боерыкны үтәү йөзеннән, хәрби комиссариат аша Михаил Девятаевны эзләп таба һәм Лесгафт урамындагы ярымподвалда яшәп ятучы гаилә белән танышырга килә. Ул язган очерк «Батырлык» дип атала, әмма «Красная Татария» үтә кискен язылган бу язманы чыгарырга кыймый. Өч айдан соң, 1957 елның 23 мартында «Литературная газета» бастырырга җөрьәт итә. Язма чыкканның икенче көнендә гади механикның язмышы бөтен ил халкына мәгълүм була. Соңрак «Советская авиация» газетасында да бу хакта сигез язма пәйда була. Шул вакытта, ни өчен бу кеше шушы көнгә кадәр Советлар Союзы Герое түгел, дигән сорау кабыргасы белән килеп баса. 1957 елның 15 августында СССР Югары Советы Президиумы Указы белән Михаил Девятаевка мактаулы исем бирелә, аларны өч бүлмәле фатир белән дә тәэмин итәләр. Әмма «Википедия»дә, Михаил Девятаевка бу исем сугышта кылган батырлыклары өчен түгел, бәлки Сергей Королев ярдәме белән ракета төзелешенә керткән өлеше өчен бирелгән булырга мөмкин, дигән сүзләр дә бар.

Александр Михайлович әйтүенчә, аның әтисе бик гади кеше була. Теләсә нинди эшкә кулы ята, балаларын да өйрәтә. Хәтта Советлар Союзы Герое исеменә лаек булу да аны үзгәртми. Берәр җирдә президиумда утырырга чакырсалар, ул аны бик авырлык белән генә кабул итә. Аның каравы укучылар белән рәхәтләнеп очраша. Хәтта бәйрәмнәрдә өйләренә барабаннар кагып, быргылар кычкыртып, пионерлар да килә торган булган. Ул аларны фатирына чакырып кунак итә.

Елга портында Девятаев 1966 елга кадәр эшли. Сәламәтлеге какшау сәбәпле, пенсиягә китә. Легендар «Ракета» совет судносын беренче тапкыр ул иярли, «Яшел Үзән»дә җыелган легендар «Метеор» теплоходының да иң беренче капитаны була.

Гаҗәп бит: әгәр Никита Хрущев үз вакытында боерык чыгармаса, үз дигәнен итеп йөрүче журналист Ян Винецкийга хәрби комиссариатта Девятаевның фамилиясен бирмәсәләр, очерк «Литературная газета»да дөнья күрмәсә… Герой онытылып калган булыр идеме икән? Александр Михайлович әйтүенчә, әтисе башта журналист белән сөйләшергә дә теләмәгән. Әнисе: «Кеше монда кадәр эзләп килгән бит инде, яхшы түгел», – дигәч кенә ачылып киткән.

Девятаевка Россия төбәкләрендә һәйкәлләр шактый куелган: туган җире Торбеевода, Вологда, Саранск, Полтава шәһәрләрендә. Ә менә күп еллар яшәгән Казан шәһәрендә аңа һәйкәл юк. Арча зиратындагы кабер өстенә бюст кына куелган. Ул укыган элеккеге Елга техникумы бинасына истәлек тактасы эленгән. Җиңү паркындагы Мәңгелек ут янындагы пантеонда элмә такта куелган. Интернеттан алынган мәгълүматлардан күренгәнчә, 2017 елда Геройның 100 еллыгы уңаеннан башкалабызда монумент кую турында карар кабул ителгән. Урыны да билгеле булган – Елга портында Иделгә карап торган урын. Девятаев анда басып, сокланып, елганы күзәтергә яраткан. Әмма соңгы мизгелдә бу урынның яраксыз булуы, аннан янгын торбалары үтүе билгеле булган. Күңелгә җылы кертә торган тагын бер яңалык бар. «Урам» экстрим-паркын ачкан вакытта территориянең бер колоннасына Девятаев портреты ясала. Димәк, Герой яшьләр күңелендә сакланыр, онытылмас дигән өмет бар әле. Әмма бу барыбер һәйкәлне алыштыра алмый инде.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Гуманитар проектларны тормышка ашыруга зур шәхси өлеш кертүе һәм актив гражданлык позициясе өчен «Снежинка» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Колотовкин** Вячеслав Геннадьевич Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авылыннан биш бала анасы **Хәмидуллина** Резеда Марс кызы Татарстан Республикасының **«Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Биология фәннәре докторы, «Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе – Казан биохимия һәм биофизика институтының оксидлашу-тернәкләндерү метаболизмы лабораториясе мөдире, баш фәнни хезмәткәре **Миңнебаева** Фәридә Вил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Кама Беконы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина-трактор паркы авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты **Белов** Юрий Ивановичка, «Август-Кама Тамагы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты **Вәлиев** Илшат Шәрифҗан улына, «САБА» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасының Саба районы) **Габдрахманов** Хәмит Кәримулла улына, «Көньяк» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасының Нурлат районы) **Егорчатов** Алексей Александровичка, «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Зеленодольск филиалы тракторчысы **Кадыйров** Шамил Нәҗип улына, «Ак Барс» агрокомплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-механизаторы (Татарстан Республикасының Арча районы) **Фәйзрахманов** Радик Рәдиф улына, «ОРСИС-АГРО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең үсемлекчелек өлкәсендә эшләүче тракторчысы (Татарстан Республикасының Түбән Кама районы) **Фролов** Василий Александровичка, «Актаныш» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Шәрипов** Айзат Илфар улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Чирмешән районы кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе **Мортазин** Әбүзәр Рәхимҗан улына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты Икътисадый анализ идарәсе инвестиция проектлары секторы мөдире **Фролов** Павел Владимировичка **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Челтәр компаниясе» акционер җәмгыятенең «Түбән Кама электр челтәрләре» филиалы Актаныш электр челтәрләре районы башлыгы **Шакиров** Марат Марсель улына **«Татарстан Республикасының атказанган энергетигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70. E-mail: vtreklama@mail.ru

ХА-ХА-ХАНӘ



Шушы урында көләсе

Булган хәлләр

УЯН, РӨСТӘМ!

«Болгар радио»сында «Чәкчәк-шоу» дигән тапшыру бар иде. Күпләр хәтерлидер. Аны Рөстәм Гайзуллин, Марсель Әхмәдуллин һәм Гөлшат Гыймадиева алып барды. Проект әче таңнан туры эфирга чыга. «Гөлшат мине уяту буенча дежур иде, – дип искә ала Гайзуллин. – Гел шалтыратып уята иде, контрольдә тота иде, йоклап калмасын дип». Беркөнне Рөстәм уянып китә, ә Гөлшат шалтыратмаган. Ярар. Бераз чәйләп ала да радиога чыгып китә бу. Гөлшат һаман шалтыратмый. Рөстәм борчыла башлый, бәлки, үзе йоклап калгандыр дип, Гыймадиевага шалтырата. Бер шалтырата, ике – алучы юк! Инде нишләргә? Гөлшат бит – алып баручы гына түгел, әле пульт артында да утырырга тиешле кеше. Шактый хафага бирелергә өлгергән Рөстәмнең берзаман башына суга – бүген шимбә көн бит, тапшыру чыкмый! Машинасы белән борыла да өенә кайтып китә.

БЕР МИНУТ ТЫНЛЫК

Журналист Рәйсә Борһаниева бервакыт Зөһрә Сәхәбиевага шалтырата. Хәл-әхвәлләрен сорашып, яңалыкларын белергә тели.

– Хәзер, телефон номерыңны блокнотыма языйм. Берәр вакыйга булса, үзем шалтыратырмын, – ди җырчы.

– Ярый.

Тынлык урнаша. Берсе дә дәшми. Ике-өч минут паузадан соң Зөһрә апа куркып кына сүз башлый:

– Алло, безнең элемтә өзелмәгәндер бит…

– Бәтәч, мин сезне блокнот алырга киттегез дип уйлыйм бит! – ди Рәйсә.

– Юк, ул минем алдымда тора. Мин сине көтеп утырам, – ди Зөһрә апа.

Мондый уңайсыз хәлдә калуларын аңлагач, икесе дә тыела алмый көләргә тотыналар.

САК БУЛЫГЫЗ: ИЛФАК – ИДЕЛДӘ

Мәрхүм хезмәттәшебез Илфак Шиһапов булган җирдә гел шаян сүз, уенкөлке була торган иде. Берзаман Илфак дуслары белән Иделгә су коенырга бара. Ярда чишенә дә йөз дә ничә килолы гәүдәсе белән әкренләп суга керә башлый. Ярда хатыны Илсөя Бәдретдинова һәм нәни улы Нариман карап тора.

– Илсөя, баланы судан бер-ике метрга читкәрәк ал әле, – дип кычкыра Илфак.

– Ник?

– Мин суга кергәч, Идел бер-ике метрга күтәрелер дип куркам.

Алтын мәзәк

Бер-берсен бик күптән күрмәгән ике дус очраша. Башта хәл-әхвәл белешәләр, өй хәлләрен сорыйлар. Баксаң, берсе эш эзли икән. Икенчесе моңа ярдәм итмәкче була:

– Карале, мин Якутиядә эшлим. Әйдә, безгә урнаш! Без алтын приискасында эшлибез.

– Кызык бу миңа! – дип куя икенчесе.

– Хезмәт хакы әйбәт чыга, әмма эше шактый ялыктыргыч. Алдан ук әйтеп куям: бер грамм алтын табар өчен, би-ик күп комны иләктән селкетергә туры килә.

– Һи! Миңа бу эш инде күптән таныш, мин «Ватаным Татарстан» газетасының «Ха-ха-ханә» сәхифәсенә мәзәкләр җыям!

Фотофакт

Моннан берничә ел элек Витебск шәһәрендә үзенчәлекле авария була. Берьюлы биш машина бер-берсенең… артына килеп бәрелә. Һи! Мондый «домино»ны Казан урамнарында да күргән бар, диярсез. Әйе. Әмма бу һәлакәтнең бер үзенчәлеге бар. Игътибар итсәгез, машиналарның барысы да «Фольксваген» маркалы. Алай гына да түгел, модельләр эволюциясе төп-төгәл сакланган! Бу машиналар бер-берсен бер урында ничек табышкан икән? Монысы безгә нәмәгълүм.

Шаян хикәя

БУТАЛУ

Гаиләдәге мөнәсәбәтләрне саклау өчен гаять зур көч таләп ителсә дә, бозар өчен артык тырышлык кирәкми. Уеннан уймак, табада коймак, мичтә бәлеш, ал да чык, дигәндәй, сәбәбе юктан гына килә дә чыга бит әле аның. Хәдичә апа да туган якларына кунакка кайтканда, четерекле вазгыять китереп чыгарырмын дип, башына да китермәгән иде. Бер кытай ыштаны бөтен эшне бозды.

Иптәшенең үлгәненә хәтсез еллар узып, үзе лаеклы ялда булса да, яшь чагында барып урнашкан Себерне ташлап китә алмады ул. Башта балалары югары уку йортын тәмамлаганын көтте. Аннан «башлы-күзле» булсыннар, диде. Инде бер-бер артлы оныклары да туа башлагач, Хәдичә апаны бөтенләе белән Себергә «ябыштырып» куйдылар. Бер караганда, өйрәнгән җир, күз күргән, колак ишеткән күрше-тирә белән җайлы, рәхәт. Аралашып яшәрдәй якташлар да җитәрлек. Шуңа күрә: «Миңа туган ягым якын булган кебек, балаларыма да кендек каны тамган җирләре якын шул», – дип, язмышына риза булып яшәвен дәвам итте. Шөкер, инде туксанга җитеп килгән әнкәсе белән әткәсе, туган-тумачалары янына һәр җәй саен кайтып, икешәр-өчәр ай торып китәргә җае гел табылып торды. Тик менә быел, кече кызының бәбәйләү вакыты май азагына туры килгәнгә, планнарга бераз үзгәреш керде. Шуңа күрә Яңа еллар үткәч кенә кайтыр юлга чыкты. Бер айлап авылда әниләре янында сагыну-юксыну хисләрен басканнан соң, поездга ике көн кала, башкалага терәлеп торган бистәдә гаиләләре белән яшәүче уртанчы энесе Тимербулат, сеңлесе Дамирага кунакка китте. Төп йортта яшәгән Ризат Хәдичә апасын ялт иттереп, туганнарына илтеп тә куйды. Бер капка төбеннән икенче капка төбенә кадәр җылы машинада барасын белгәнгә, Хәдичә апа чалбар эченнән киеп йөри торган җылы кытай ыштанын сумкасына салып куйды.

Беренче көнне ул Тимербулатларда кунды. Сеңлесе дә иптәше белән килделәр. Туганнар кич буе гөрләшеп-серләшеп утырдылар. «Апа, барыбер иртәгә поездга бездән кузгаласың», – дип, Дамиралар юл сумкаларын үзләре белән алып китте. «Ярый, бигрәк әйбәт, ерак ара түгел, иртәгә сезгә иркенләп, саф һава сулый-сулый гына барырмын», – диде Хәдичә апа. Фәридә дә: «Әйе, дөрес, үзем озата барырмын, апа», – дип хуплады. Иртән ул, коридордан төшкән яктылыкка риза булып, йокы бүлмәсендәге утны кабызмый гына киенде. Җәяүләп кенә барасын уйлап, урындык артында эленеп торган ыштанны да киеп куйды.

Икенче көнне, сеңелләрендә поездга җыенып йөргәндә, сумкасын ачып караса, ыштаны монда ята! Әйе шул, авылда юлга җыенганда, кирәге чыкканда тиз генә алып киярге, өстә генә торсын, дип куйган иде ләбаса! «И юньсез, тегеләрнең ыштанын киеп киткән булып чыгам түгелме соң?! Әйтәм аны, зуррак кебек тоелды. Кайсы базарны карама, шул бер төрле әйбер бит, инкубаторскийга әйләнеп беттек», – дип сөйләнә-сөйләнә, үзенекен алыштырып киде. Фәридәгә ыштан турында телефоннан хәбәр итмәкче булган иде, шул чакта олы кызыннан шалтырату килеп, өлгерә алмый калды. Кызы белән сөйләшеп бетүгә, Дамира белән Газим ишегалдындагы иртәнге эшләрен бетереп керделәр. Шуннан җыелышып табынга утырдылар, ыштан онытылды.

Хуш, Хәдичә апагыз бу минутларда поездга утырып, Себергә кайтып бара. Ә бу вакытта ике гаиләдә…

Урындык артына куелган ыштанны эзләп-эзләп тә тапмагач, Тимербулат белән Фәридә ни уйларга да белмәде.

– Әллә берәрсен ияләштердең инде, мин балыкка йөргәндә, бәгырь?

– Миннән гаеп эзләгәнче, үзеңне кара! Балык дигәнең, таллык булмады микән, кая ыштаның?!

– Әйе шул! Су анасы өшегән иде, аңа кидереп калдырдым!

– Сүзеңне шаяруга борма, яме!

– Мин бик җитди, бәгырь!



Ярый, болар сүз көрәштерә торсын, без Дамираларга күчик. Әйтергә кирәк, Дамира үзе дә, тормыш иптәше Газим дә үтә дә пөхтәлек, тәртип ярата торган кешеләрдән. Аларның капкаларын ачып керү белән, хуҗаларның кем икәне күзгә ярылып ята: бөтен җирдә тәртип. Газимнең төзелеш өлкәсендә эшләве дә иш янына куш кына. Улларын да шулай тәрбияләделәр – һәрбер әйбернең үз урыны булырга тиеш! Шуңа күрә киленнәре дә аларга рәхмәтле. Хәдичә калдырып киткән ыштанга беренче булып Газимнең күзе төште.

– Җаный, бу нинди ир-атлар ыштаны ул?

– Белми-и-им. Малайларның берәрсенеке дисәм, атна-ун көн килгәннәре юк.

– Малайлар килмәгәч, кем онытып калдырган соң? Әллә бажаймы?

– Кит, язмаган сүз сөйләп торма әле, ачуымны китереп! Үзең алыштырып кайткансыңдыр әле берәрсе яныннан!

Газим, хатын-кыз белән сүз көрәштерүнең мәгънәсезлек икәнен белгәнгә: «Ярый, бажайга илтеп бирермен, адресын әйтерсең», – дип, ишеккә таба юнәлде. Шул вакытта пуля кебек атылып килеп кергән Фәридә чак төртеп екмады үзен. «Уф-ф-ф!» – дип, ишек яңагына килеп сөялгән җиңгиләрен Газим белән Дамира, әле генә үзара чәкәләшеп алганнарын онытып, тынычландырырга керештеләр. «Тимербулат ыштанын кемдәдер калдырып кайткан да хәзер миннән таптыра. Җитмәсә, хыянәттә гаепли», – дигәч, эшнең нәрсәдә икәнен тиз генә чамалап алган хуҗалар бер-берсенә карадылар да көлеп җибәрделәр. Дамира җәһәт кенә йокы бүлмәсеннән кулына ыштан тотып чыкты.

– Абыйныкымы?

– Әйе. Сезгә каян килеп кергән ул?

– Менә шуны уйлап, баш ватып утыра идек әле без дә, әйеме, күгәрченкәем!

Бу минутларда Хәдичә апаларының купеда, авыл күчтәнәчләре белән тәмләп кенә чәй эчәргә әзерләнеп йөргән чагы иде. Кинәт, келт итеп, исенә шалтыратасы барлыгы килеп төште. Ул телефоннан сеңлесенең номерын җыйды: «Карале, Дамира, Тимербулатларда буталып, кайсысыныңдыр ыштанын кигәнмен. Сезнең йокы бүлмәгездә калдырып киттем, тапшырырсың әле шуны үзләренә, яме!» Кызганычкамы, бәхеткәме, Хәдичә апа җавап сүзен ишетә алмый калды – поезд, кәрәзле элемтә тотмый торган урынга килеп керде дә, сөйләшү өзелде. Үзегез дә чамаладыгыз бугай инде Хәдичә апагызның ни ишетәчәген.

Люция ӘБЛИЕВА

Белеп тор!

ҺӘР ИР-АТ МОНЫ ЭШЛӘРГӘ ТИЕШ

- Хатыны күрмәгәндә, песине тузан суыргыч белән чистартырга.
- Келәмне төреп урамга алып чыккач, аны гранатомёт сыман тотып, кошларга атарга.
- Чалбар кесәсе аша трусигын рәтләргә.
- Берәрсе авыз ачып иснәнсә, авызына бармак тыгарга.
- Күлмәк үтүкләнсен өчен, аны бер тәүлеккә урындык башына элеп куярга.
- Ваннада чәчен артка тарап, үзен итальян мафиозие итеп тоярга.
- Душта шампунь белән бөтен тәнне юарга.



Җавап тап!

Табышмак әйтәм

Машинаның шундый бер детале була, ул машинаның үзенә караганда да күбрәк чакрымнар уза. Нинди деталь бу?

Табышмак җавабы: машина ачкычы.

Булмас аны ватып…

Роберт МИҢНУЛЛИН

Бабайлар да күккә ашып торган
Манаралар корган.
Сары айлы кәрвансарайлары
Горур басып торган!

Тик җир белән тигезләгән барсын
Мәрхәмәтсез Вакыт.
Безгә балчык чүлмәк кенә калган –
Анысы да ватык.

Ул чүлмәкне кыйпылчыкларыннан
Җыйганнардыр көчкә.
Гап-гади буш чүлмәк. Гыйфрите дә,
Чурты да юк эчтә…

Бездән соң да чүлмәк калыр микән?
Ниләр эшләр Вакыт?!
Тик ул балчык булмас! Болай гына
Булмас аны ватып!

Фотомәзәк

Үтүгемне фотога төшереп, сатуга куйган идем. Никтер берәү дә шалтыратмый…

Әз-мәз мәзәк

Кайвакыт ятып торасы килә. Әмма инде болай да яткан икәнең исеңә төшә.

* * *

Кичә бер адәм тукталышта эте белән сөйләшеп утыра иде. Бигрәк сәер күренеш. Кайтып мәчегә сөйләгән идем, икебез дә шаркылдап көлдек.

* * *

– Син нинди комарлы уеннар уйныйсың?
– Кешеләргә ышанам, мәсәлән.

* * *

Минем шатлыкны бүлешергә кирәкми. Үзеңнекен бүлеш. Минем шатлыкка тимә.

* * *

Кызлар, йолдызнамәгә ышаныгыз. Үлчәүләр алдамый. Сез, чыннан да, бераз тазарып киткәнсез.

* * *

– Көн саен яңа урыннар, яңа кешеләр белән очрашам…
– Командировкаларга йөрисеңме?
– Юк. Склероз.

* * *

Күпчелек кешеләр акыллы. Әмма миңа ни өчендер гел азчылык очрый.

* * *

– Лилия, карале, Марат сине ярата бугай, гел артыңнан йөри.
– Юк. Әҗәткә акча алып торган идем мин аннан.

* * *

Бөтен бәла хатын-кыздан. Килешмисез икән, димәк, сез – хатын-кыз.

* * *

Балачакта бөтен кеше бәхетле. Чөнки аларны бәхетле киләчәк көтә.

Мач әйткән!

ПЕЛЕ,
Бразилия футболчысы

Әгәр син беренче икән, син – беренче. Әгәр син икенче икән, син беркем түгел.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.

Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5322 данә
Гомуми тираж – 15277 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 221

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+